| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| **РАСПОРЯЖЕНИЕ** | **БОЕРЫК** |

«10» февраля 2021 с. Тюлячи № 22

Теләче муниципаль районы мигрантларын 2021 елда социаль, мәдәни адаптацияләү һәм интеграцияләү буенча чаралар планын раслау турында

Район Башкарма комитеты мәгариф бүлегенең 2021 елның 1 февралендәге 6 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 9 декабрендәге 538 номерлы карары белән расланган «2021-2023 елларга Теләче муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» муниципаль программасын гамәлгә ашыру максатларында,

1. Теләче муниципаль районы мигрантларын 2021 елда социаль, мәдәни адаптацияләү һәм интеграцияләү буенча чаралар планын (алга таба текст буенча - План) кушымта нигезендә расларга.

2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлегенә (Иксанов Д.С.):

2.1. Ведомство карамагындагы мәдәният учреждениеләрендә планны гамәлгә ашыру буенча җаваплы вазыйфаи затны билгеләргә.

2.2. Квартал саен планны тормышка ашыруга анализ ясарга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«10» февраль 2021 № 22
боерыгына кушымта

**Мигрантларны социаль, мәдәни адаптацияләү һәм интеграцияләү буенча чаралар планы**

| № т/б | Чаралар атамасы | Үтәү вакыты | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1. | Теләче муниципаль районында яшәүче халыкларның милли мәдәниятен һәм телләрен пропагандалауга юнәлдерелгән район милли бәйрәмнәрендә һәм башка муниципаль чараларда катнашуга мигрантларны җәлеп итү.<br>Теләче муниципаль районында чит ил гражданнарын адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә ярдәм итү | 2021 ел | КДУ директоры |
| 2. | Мигрантлар һәм аларның гаиләләре өчен музейга баруны оештыру | Ел дәвамында | Теләче туган якны өйрәнү музее |
| 3. | «Нәүрүз» бәйрәмен үткәрү | Март | Р.М. Дәүлиева<br>Ф.М. Нәгыймова |
| 4. | Агитбригаданың «Теләче» сәнәгать паркына концерт программасы белән баруы | Июль 2021 ел | Директор вазыйфаларын башкаручы Ф.М. Нагимова<br>Район мәдәният йорты хормейстеры Поташова А.Б. |
| 5. | «Дуслык күпере» район сувенир фестивале | Сентябрь 2021 ел | Директор вазыйфаларын башкаручы Ф.М. Нагимова |
| 6. | «Халыкның бердәмлеге - ил бердәмлеге» Халыклар бердәмлеге көненә багышланган тантаналы чара үткәрү | 4 ноябрь 2021 ел | Директор вазыйфаларын башкаручы Ф.М. Нагимова |
| 7. | «Төрки кино» милли кинофильмнар күрсәтү | Июнь 2021 ел | Район мәдәният йорты МБУ киноогператоры |
| 8. | «Таҗикстан Конституциясе көне» - милли кинофильмнар күрсәтү | Ноябрь 2021 ел | Район мәдәният йорты МБУ киноогператоры |
| 9. | «Без бергә, без бердәм» - буклет ясау һәм тарату | 19.02.2021 | Казаклар үзәк китапханәсе |
| 10. | «Булсак та без төрле милләттән...» - дуслык сәгате | 04.11.2021 | Казаклар үзәк китапханәсе |
| 11. | «Үз телеңне яхшы бел, Татарча да яхшы бел. Авылдашлар белән аралашу | Регуляр | Рәхмәтуллина А.А. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | өчен икесе дә кирәк тел.» Татар китаплары, периодикасы белән танышу | рәвештә | |
| 12. | Мигрантларның Балалар китабы атналыгында катнашуын оештырырга (программада: «Дөнья әкиятләре» әкият терапиясе, уен - «Китап Сезнең өчен бәйрәм булсын!», «Театраль сандык» уен программасы) | Март 2021 | Теләче үзәк китапханәсе |
| 13. | «Тукай әкиятләренә ияреп» мигрантларның рәсем һәм кул эшләре конкурсында катнашуын оештырырга | Апрель 2021 | Теләче үзәк китапханәсе |
| 14. | Мигрантларның «Мәхәббәт җылысы булган гаилә һәрвакыт ышанычлы һәм ныклы» китап укучылар аралашуында катнашуын оештырырга | Июль 2021 | Теләче үзәк китапханәсе |
| 15. | Мигрантларның «Толерантлык - тынычлыкка юл» чарасында катнашуын оештырырга | Ноябрь 2021 | Теләче үзәк китапханәсе |
| 16. | Уку формулярларын анализлау | Гыйнвар | Үзәк авыл китапханәсе |
| 17. | «Туган тел» квест-уенында мигрант балаларның катнашуы һәм оештыру | 12 февраль | Үзәк авыл китапханәсе |
| 18. | Мигрант балаларның туган тел көненә багышланган «Иң татлысы - Туган тел» дигән әдәби кичәдә катнашуын оештырырга | 20 февраль | Үзәк авыл китапханәсе, Үзәк авыл мәдәният йорты, Максабаш авыл мәдәният йорты, Максабаш авыл китапханәсе |
| 19. | Мигрант балаларның «Синең толерантлык индексы: 10 нәтиҗәле аралашу ысулы» толерантлык дәресендә катнашуын оештырырга | 5 март | Үзәк авыл китапханәсе, Үзәк авыл мәдәният йорты, Максабаш авыл мәдәният йорты, Максабаш авыл китапханәсе |
| 20. | Хатын-кыз мигрантларның «Галиҗәнап хатын-кыз...» кичәсендә катнашуларын оештырырга | 8 март | Үзәк авыл китапханәсе |
| 21. | Мигрант балаларның табигать турындагы китаплар буенча «Мин китап белән табигать дөньясын ачам…» рәсемнәр күргәзмәсендә катнашуын оештырырга | 5 апрель | Үзәк авыл китапханәсе |
| 22. | Туган телдә рус теленә параллель тәрҗемә белән шигырьләр уку | 10 апрель | Үзәк авыл китапханәсе |
| 23. | Җиңү көненә багышланган чараларда мигрантларның катнашуын оештырырга | 9 май | Үзәк авыл китапханәсе, Үзәк авыл мәдәният йорты, Максабаш авыл мәдәният йорты, Максабаш авыл китапханәсе, Алан авыл китапханәсе |
| 24. | Мигрант балаларның Җәйге китап укуларда катнашуын оештыру | Июнь | Үзәк авыл китапханәсе |
| 25. | Җәйге мәйданда мигрант балаларга хезмәт күрсәтү: «Чәчәкләр белән җир елмая» (игелекле эшләр акциясе - китапханә янында чәчәк түтәлләре ясау) акциясе, асфальтта «Чәчәкләр» дигән балалар рәсемнәре конкурсы | Июль | Үзәк авыл китапханәсе, Үзәк мәдәният йорты |
| 26. | Татарстан Республикасы көненә багышланган чараларда мигрантларның катнашуын оештыру | Август | Үзәк авыл китапханәсе, Үзәк мәдәният йорты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 27. | «Ишегалдына укырга чык» акциясендә катнашуга җәлеп итү | Август | Үзәк авыл китапханәсе |
| 28. | Терроризмга каршы көрәш буенча Бердәмлек көненә багышланган чарада – «Беслан кайгысы кайтавазы» хәтер дәресендә катнашуны оештыру | 3 сентябрь | Үзәк авыл китапханәсе, Үзәк мәдәният йорты |
| 29. | «Яшьләр - тынычлык өчен, террорчылыкка каршы» плакатлар конкурсында катнашу | 7 сентябрь | Үзәк авыл китапханәсе, Үзәк мәдәният йорты |
| 30. | «Барысы да ана кулыннан» (Әниләр көненә) әниләр бәйрәмендә мигрантларның катнашуын оештыру | 3 ноябрь | Үзәк авыл китапханәсе, Үзәк мәдәният йорты |
| 31. | «Минем илемнең нигезе» Россия Федерациясе Конституциясе көненә багышланган телдән журналда мигрантларның катнашуын оештыру | 12 декабрь | Үзәк авыл китапханәсе |
| 32. | «Китап килә сезнең өйгә» - акция<br>«Китап белән бергә кояшлы җәйгә» - җәйге китап уку залы-проект | Регуляр рәвештә<br>Җәйге чор | Иске Җөри авыл китапханәсе, Иске Җөри авыл мәдәният йорты |
| 33. | Өйдә китаплар һәм периодика белән мигрантларга хезмәт күрсәтү, җирле традицияләр һәм гореф-гадәтләр турында әңгәмәләр | Регуляр рәвештә | Алан авыл китапханәсе |
| 34. | Туган тел көненә багышланган «Мин татарча, саф татарча уйлыйм, көйлим, сөйләшәм!» чарасында мигрант балаларның катнашуын оештыру | Февраль | Алан авыл китапханәсе |
| 35. | Мигрантлар гаиләләренең өйләренә барып, әңгәмә - гаилә әгъзаларын Милли бәйрәмнәр белән таныштыру. «Бер-беребез турында беләбез - бер-беребездән беләбез!» | Март | Алан авыл китапханәсе |
| 36. | «Китапханәдә балалар китабы көне» - мигрант балаларның чарада катнашуын оештырырга | Апрель | Алан авыл китапханәсе |
| 37. | Балаларны яклау көненә багышланган чарада мигрант балаларның катнашуын оештыру | Июнь | Алан авыл китапханәсе |
| 38. | Мигрант балаларның табигать турындагы китаплар буенча «Мин китап белән табигать дөньясын ачам…» рәсемнәр күргәзмәсендә катнашуын оештырырга | Октябрь | Алан авыл китапханәсе |
| 39. | Рус теленә параллель тәрҗемә белән татар телендә шигырьләр һәм әкиятләр уку | Сентябрь | Алан авыл китапханәсе |
| 40. | Җиңү көненә багышланган чараларда мигрантларның катнашуын оештырырга | 9 май | Алан авыл китапханәсе |
| 41. | Мигрант балаларның Җәйге китап укуларда катнашуын оештыру | Июнь | Алан авыл китапханәсе |
| 42. | «Без төрле, әмма без бергә!» - патриотик сәгать | Ноябрь | Алан авыл китапханәсе |

Эшләр идарәчесе И.Т. Һадиев